

Музей картаймый, ә елдан-ел яхшыра бара. 10 январьда С.Д.Эрьзя исемендәге республика сынлы сәнгать музее 64 яшьлек юбилеен билгеләп vтте. Скульпторнын эшләрен илебезнен торле музейларында кvрергә була. Степан Эрьзя әсәрләренен ин зур кvргәзмәсе - 200 дән артык эш - анын исемен йорткән Мордовия Республикасынын сынлы сәнгать музеенда.
Мордовия Главасы Артём Здунов кушуы буенча, музей хезмәткәрләрен матур дата белән Мәдәният, милли сәясәт һәм архив эше министрынын беренче урынбасары Александр Карьгин котлаган.      - Узган елларда, әлбәттә, музейнын интерьерларында да, ижади эшчән-легендә дә кvп нәрсә vзгәрде, - дип билгеләп vтте министр урынбасары. - Әмма ин моһиме, анын турында торле континентларда беләләр. Һәм торле тобәкләрдән килгән кунаклар, рес-публикага килгәч, гениаль скульптор С.Д.Эрьзя талантынын рухи коче белән тукланыр очен, музейга килергә тырышалар.
- Бvген безгә 64 яшь тулды. Музей тарихы бай һәм кvпкырлы, - дип искәртте Саранск сәнгать гыйбадәтханәсе жи-тәкчесе (С.Д.Эрьзя исемендәге музей директоры) Людмила Нарбекова.
- Берничә ел элек Россия Президенты Владимир Путин хуплавы белән без бинаны капиталь реконструкцияләvгә, экспозиция мәйданнарын кинәйтvгә һәм яна депозитарий тозvгә ирештек. Музей очен 64 яшь - бу, әйтерсен лә, житлеккән яшьлек. Һәм сәнгать коллекциясен формалаштыруга, заманча музей булдыруга олеш керткән һәркемгә рәхмәт әйтергә кирәк: һәм мәдәниятkә, һәм сәнгатькә намуслы, тугры хезмәт итvләрен дәвам итvчеләргә.
Январьнын беренче атнасында сәнгать гыйбадәтханәсенә 4 мен кеше килгән. Шулай ук музей аккаунтларыннан социаль челтәрләрдә 64 яшьлек Юбилейлары унаеннан яхшы сvзләрне калдырганнар. Комментарийлар арасында журналистлар, рәссамнар, сәнгатьне бәяләvчеләр бар.
Н.ХӘЛИЛ